**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 24.12.2020** **№ 962**

# 2017-2022 елларга Биектау муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 27 октябрендәге 1747 номерлы «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру үзенчәлекләренең 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында» Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 06.03.2020 № 243 карары белән расланган «Биектау муниципаль районында 2017-2022 елларга яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» Муниципаль программасының 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 пунктның «а» пунктчасында «әлеге Кагыйдәләргә 1 нче кушымта» сүзләреннән соң «(яшәү урыны буенча җирле үзидарә органына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә)» сүзләрен өстәргә;

2) 18 пунктта «язмача» сүзеннән соң «яисә электрон рәвештә Бердәм портал юлы белән» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р.Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин